ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 7 (II өлеш); 2009, № 7-8 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 – 6 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**"Спас муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге территориясе чигенең
картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы"

муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Спас муниципаль районы Ульяновск өлкәсе, Тәтеш, Кама Тамагы, Лаеш, Алексеевск һәм Әлки муниципаль районнары белән чиктәш.

"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Әлки, Спас муниципаль районнарының һәм Ульяновск өлкәсенең чикләре тоташкан урында Нәлет авылыннан 300 м көньяк-көнчыгышка таба урнашкан 40 нчы (2 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас, Тәтеш муниципаль районнарының һәм Ульяновск өлкәсенең чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 9 нчы (3 нче) тоташу ноктасына кадәр сузыла.

"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 9 нчы (3 нче) тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча Кама Тамагы, Спас һәм Тәтеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1 нче (34 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 40 нчы (2 нче) тоташу ноктасыннан алып "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 140, 131, 123 нче урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 5,4 км төньяк-көнчыгышка, 8 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м уза, аннары 8 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 50 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, алга таба әлеге инеш агымы буенча аска таба 1,6 км Юхмачы елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча өскә таба 750 м, 5 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 20 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 400 м, көньяк-көнбатышка 250 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 110, 121, 120, 119, 118 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап 6,8 км уза, Майна елгасын һәм Барановский инешен кисеп үтеп, 118, 105, 92 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча, сынык сызык ясап, 7,0 км төньяк-көнбатышка уза, аннары 92, 80, 73 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 3,0 км бара, 73 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча, сынык сызык ясап, 500 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,7 км, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 32 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буенча, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 1,4 км һәм көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 700 м бара, 30 нчы, 31 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча 750 м көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, 32 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш, көньяк һәм көнбатыш чикләре һәм 31 нче урман кварталының көньяк чиге буенча көнбатышка 2,1 км бара, аннары 31 нче

урман кварталының көнбатыш чиге буенча, сынык сызык ясап, төньякка 1,4 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 850 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап төньякка 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м, урман массивының көнбатыш чиге буенча 250 м бара, тагын авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м, урман массивы буенча кибеп баручы инешкә кадәр 200 м уза, алга таба әлеге инеш агымы буенча буага кадәр 400 м дәвам итә, аннары буа буйлап төньяк-көнчыгышка 100 м, кибеп баручы инеш агымы буенча тагын аска таба 4,4 км аның Утка елгасына кушылган җиренә кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча өскә таба 450 м уза, яр буендагы агач-куаклыклар полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 800 м бара, аннары урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 150 м, Югары Колчурино – Катюшино автомобиль юлын һәм Кузнечиха авылына керү юлын тоташтыра торган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 200 м, 14 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 1,2 км бара, алга таба 14 нче, 12 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча, сынык сызык ясап, төньякка 2,6 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 100 м, урман массивы буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 900 м һәм, сынык сызык ясап, көнбатышка 400 м, сынык сызык ясап, чокыр төбе буенча төньяк-көнбатышка 650 м дәвам итә, кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 1,6 км, чокыр кырыен кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка 100 м бара, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м, 6 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча, сынык сызык ясап, төньякка 1,3 км бара, аннары урман массивы буенча төньяк-көнчыгышка 20 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буенча төньякка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км, урман полосасының көнчыгыш чиге буенча 150 м, 75 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 350 м дәвам итә, алга таба яңадан әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 1,0 км, урман полосасы буенча 150 м бара, аннары урман полосасының көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 50 м, урман полосасы буенча 600 м бара, аннары, "КИМ" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка" – Фадеевка һәм Кошки – Чуаш Шәпкәсе автомобиль юлларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м уза, урман полосасы буенча 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, Бездна елгасының сулъяк ярындагы кыялы кишәрлекне һәм елганың үзен кисеп үтеп, кибеп баручы инеш борынына кадәр авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м бара, аннары әлеге инеш агымы буенча өскә таба 1,8 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка 700 м һәм төньяк-көнбатышка 25 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 1,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 700 м төньяк-көнбатышка һәм, сынык сызык

ясап, төньяк-көнчыгышка 2,4 км, Тахтала инешен һәм чокырларны кисеп үтеп, урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буенча 400 м бара, сынык сызык ясап, төньякка "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 88 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 400 м төньякка уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка 250 м һәм көнбатышка 200 м, урман массивы буенча 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м бара, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка урман утыртмаларының төньяк чиге буенча 1,1 км, 86 нчы, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буенча 2,2 км уза, алга таба төньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 84 нче, 85 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча 1,7 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, 750 м уза, аннары урман массивының көнчыгыш чиге буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буенча төньяк-көнчыгышка 1,3 км, урман массивы буенча төньякка 15 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман массивы буенча 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, урман массивы буенча 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,2 км, 75, 76, 77 нче урман кварталларының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнчыгышка 2,7 км уза, аннары, сынык сызык ясап, 78 нче, 74 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка 1,8 км, 74 нче, 73 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 3,5 км бара, алга таба 73 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 71 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча төньякка 1,8 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка 450 м, сынык сызык ясап, 69 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 500 м бара, алга таба, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 6,0 км уза, аннары урман массивы буенча төньяк-көнбатышка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, төньяк-көнчыгышка 1,3 км һәм төньяк-көнбатышка 500 м, 56 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 3,5 км Әлки, Алексеевск, Спас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Танино авылыннан 5,8 км төньяк-көнчыгышта, үләт чокырыннан 0,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче (31 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче (31 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,6 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 3,5 км, көнбатышка 950 м, төньяк-көнбатышка 550 м, төньяк-көнчыгышка 6,2 км, төньяк-көнбатышка 450 м уза, аннары күл буенча 100 м бара, алга таба кабат авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 300 м һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка Актай елгасына кадәр 700 м уза, аннары әлеге елга агымы буенча аска таба 3,7 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка, чокырлы кишәрлекләрне, чокырларны һәм Актай елгасын кисеп үтеп, 3,2 км уза, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 250 м, "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет

учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 950 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 2 нче, 3 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча көнчыгышка 2,1 км бара, аннары, сынык сызык ясап, 3 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буенча төньяк-көнбатышка 2,1 км уза, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча Алексеевск, Спас һәм Лаеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Коминтерн поселогыннан 11,6 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 24 нче (32 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге Лаеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 24 нче (32 нче) тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча көньяк-көнбатышка 26,0 км, сынык сызык ясап, Кама Тамагы, Лаеш һәм Спас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Әҗмәр авылыннан 12,1 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 20 нче (33 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә 20 нче (33 нче) тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 1 нче (34 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең**
**картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге Приволжский, Өчкүл авыл җирлекләре, Кама Тамагы һәм Тәтеш муниципаль районнары белән чиктәш.

"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге, Өчкүл авыл җирлеге һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Үрнәк авылыннан 5,3 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 4 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге, Тәтеш һәм Кама Тамагы муниципаль районнары чикләре

тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1нче (34 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә 1 нче (34 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге, Приволжский авыл җирлеге һәм Кама тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 7,3 км төньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Приволжский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньякка 8,4 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча сулъяк ярга кадәр уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 200 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырларны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 650 м, көнбатышка 350 м, көньяк-көнчыгышка 100 м аэродромга кадәр бара, аэродром буенча көньяк-көнчыгышка 650 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 650 м, төньяк-көнчыгышка 700 м, саклау валын һәм "Базарлы Матак – Болгар" – Ржавец автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка 1,0 км, көньяк-көнбатышка 150 м уза, аннары көньякка урман массивының көнбатыш чиге буенча 150 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка, урман массивын һәм сакланулы урман полосасын кисеп үтеп, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр 750 м бара, аннары әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буенча көнчыгышка 600 м, алга таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 300 м "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге, Приволжский һәм Өчкүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 3,1 км көньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 50 м, урман массивының төньяк чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча Болгар – Танкеевка автомобиль юлына кадәр 1,2 км бара, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буенча көньякка 750 м уза, аннары, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 350 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 29 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап көньяк-көнбатышка 1,3 км һәм 28 нче урман кварталы буйлап 1,7 км бара, аннары 28 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка 2,5 км уза, алга таба 14, 13, 12 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча көнбатышка 3,1 км Куйбышев сусаклагычының сулъяк ярына кадәр уза, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 2,0 км 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Аграмак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Аграмак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Аграмак авыл җирлеге Антоновка, "КИМ", Урта Йорткүл, Ямбакты авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы белән чиктәш.

Аграмак авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә Аграмак, Ямбакты авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ямбакты авылыннан 4,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Аграмак, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Аграмак авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 150 м Аграмак, Урта Йорткүл һәм Антоновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Аграмак авыл җирлеге чиге Антоновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, урман полосасын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка 1,4 км бара, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, урман полосасы буйлап 500 м бара, алга таба, ике тапкыр сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,0 км, көнбатышка 1,0 км, Антоновка – Татар Такталысы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 2,7 км, Наясолка елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 2,6 км һәм төньяк-көнбатышка 400 м уза, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 1,4 км Аграмак, Антоновка һәм «КИМ» авыл җирлекләре тоташкан урында Тукай авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Аграмак авыл җирлеге чиге "КИМ" авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аграмак, "КИМ", Ямбакты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай

авылыннан 3,8 км көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка 3,1 км Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлы буйлап бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 450 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 700 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 1,3 км 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Аграмак авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып 3,5 км төньяк-көнбатышка Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 3,5 км бара, аннары, әлеге автомобиль юлын һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 100 м бара, алга таба "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 63 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча көньякка 650 м һәм көньяк чиге буенча көнбатышка 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка 550 м, төньяк-көнбатышка 100 м бара, аннары 65 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 950 м, төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 250 м, көнбатыш чиге буйлап көньякка 200 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 350 м уза, алга таба, урман массивын, урман полосасын һәм Аграмак – Ямбакты автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 2,1 км бара, шуннан соң 64 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап көньякка 400 м, урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м уза, аннары әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча көньякка 350 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка 450 м дәвам итә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 100 м, әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м бара, аннары 61 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км һәм, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"<br>Татарстан Республикасы Законына<br>5 нче кушымта

**Спас муниципаль районының "Антоновка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Антоновка авыл җирлеге" муниципаль

берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Антоновка авыл җирлеге Аграмак, "КИМ", Никольский, Урта Йорткүл авыл җирлекләре белән чиктәш.

Антоновка авыл җирлеге чиге "КИМ" авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Антоновка, "КИМ" һәм Аграмак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка 200 м, алга таба көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 800 м, сазлыкның көньяк чиге буйлап 50 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 500 м "Алексеевск – Югары Колок" – Базяково – Тукай автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап төньякка 300 м бара, аннары көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, сазлыкның төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, сазлыкның төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 150 м һәм, "КИМ" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кабат авыл хуҗалыгы җирләре буенча 2,4 км уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 300 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 1,4 км, көньяк-көнчыгышка 150 м һәм кабат көньяк-көнбатышка 450 м Антоновка, "КИМ" һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында "КИМ" совхозының икенче ферма поселогыннан 3,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Антоновка авыл җирлеге чиге Аграмак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Антоновка, Аграмак һәм Урта Йорткүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,4 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, урман полосасы буйлап 500 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, ике тапкыр сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка 1,0 км, көнбатышка 1,0 км, Антоновка – Татар Такталысы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка 2,7 км, Наясолка елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка 2,6 км һәм төньяк-көнбатышка 400 м уза, аннары төньяк-көнбатышка 650 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Антоновка авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км, "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет

учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м бара, Бездна елгасын, яр буе агач-куак массивын, сазлыкны һәм "КИМ" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 4,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча Антоновка, Урта Йорткүл һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан җирдә Кырый Йорткүл авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Антоновка авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 750 м, сазлык буйлап 200 м, күл буйлап 100 м уза, алга таба төньяк-көнчыгышка сазлык буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасы буенча 2,5 км, сазлык буйлап 100 м Лахтур инешенә кадәр бара, аннары әлеге инеш агымы буенча 450 м аска таба буага кадәр уза, әлеге буаның уңъяк яры буйлап төньяк-көнбатышка 2,8 км бара, алга таба "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка 300 м уза, аннары төньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кабат 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 700 м бара, алга таба 40 нчы, 41 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 2,2 км уза, аннары 41, 39, 37 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,4 км төньяк-көнбатышка 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында" Татарстан Республикасы Законына
6 нчы кушымта

**Спас муниципаль районының
"Бураково авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге
территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Бураково авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Бураково авыл җирлеге Әҗмәр, Ямбакты авыл җирлекләре, Алексеевск һәм Лаеш муниципаль районнары белән чиктәш.

Бураково авыл җирлеге чиге Лаеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә Бураково, Әҗмәр авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Коминтерн поселогыннан 7,7 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Бураково авыл җирлеге, Лаеш һәм Алексеевск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Коминтерн поселогыннан 11,6 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 24 нче (32 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Бураково авыл җирлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 24 нче (32 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Бураково, Ямбакты авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Танино авылыннан 3,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Бураково авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 2,2 км, көньякка 650 м, төньяк-көнбатышка 250 м уза, аннары "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнбатышка 850 м һәм көнбатыш чиге буенча көньякка 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 200 м, көньяк-көнбатышка 400 м, төньякка 2,0 км, көнбатышка 1,4 км урман полосасына кадәр уза, әлеге урман полосасының көньяк чиге буенча көнбатышка 450 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 700 м, урман массивын кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнбатышка Бураково, Ямбакты һәм Әҗмәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ямбакты авылыннан 5,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бураково авыл җирлеге чиге Әҗмәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 8,5 км аның сулъяк ярына кадәр уза, аннары "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 20 нче, 21 нче урман кварталларының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнчыгышка 2,9 км бара, алга таба көньяк-көнбатышка 21 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 550 м уза, аннары 21 нче, 22 нче урман кварталлары буенча көньяк-көнбатышка 600 м, көньяк-көнчыгышка 1,3 км дәвам итә, шуннан соң көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча, канауны кисеп үтеп, Актай елгасына кадәр 650 м уза, әлеге елга агымы буенча 1,4 км аска таба аңа Сушка елгасы койган җиргә кадәр бара, Сушка елгасы агымы буенча, "Алексеевск – Югары Колок" – Базяково – Тукай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 9,0 км өскә таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка кибеп баручы инеш агымы буенча 700 м өскә таба һәм кабат Сушка елгасы агымы буенча 650 м өскә таба 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза. ";

2) 8 – 20 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
8 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Әҗмәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Әҗмәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Әҗмәр авыл җирлеге Бураково, Куралово, Ямбакты авыл җирлекләре, Кама Тамагы һәм Лаеш муниципаль районнары белән чиктәш.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Әҗмәр, Куралово авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Әҗмәр авылыннан 7,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=405887,08, Y=1324434,98 координаталы 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Әҗмәр авыл җирлеге, Кама Тамагы һәм Лаеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Әҗмәр авылыннан 12,1 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 20 нче (33 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Лаеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 20 нче (33 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Әҗмәр, Бураково авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Коминтерн поселогыннан 7,7 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Бураково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 8,5 км аның сулъяк ярына кадәр уза, аннары "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 20 нче, 21 нче урман кварталларының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнчыгышка 2,9 км бара, алга таба көньяк-көнбатышка 21 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 550 м уза, шуннан соң 21 нче, 22 нче урман кварталлары буенча көньяк-көнбатышка 600 м, көньяк-көнчыгышка 1,3 км дәвам итә, аннары көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча, канауны кисеп үтеп, Актай елгасына кадәр 650 м уза, әлеге елга агымы буенча 1,4 км аска таба аңа Сушка елгасы койган җиргә кадәр бара, Сушка елгасы агымы буенча, "Алексеевск – Югары Колок" – Базяково – Тукай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 9,0 км өскә таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка кибеп баручы инеш

агымы буенча 700 м өскә таба һәм кабат Сушка елгасы агымы буенча 650 м өскә таба Әҗмәр, Бураково һәм Ямбакты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ямбакты авылыннан 5,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр дәвам итә.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, урман полосасы буенча 450 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м Әҗмәр, Ямбакты һәм Куралово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Екатериновка авылыннан 4,4 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әҗмәр авыл җирлеге чиге Куралово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 12,2 км көньяк-көнчыгышка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап сусаклагычка инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 1,7 км өскә таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка сазлык буенча 50 м, сазлыкның төньяк чиге буенча 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м Әҗмәр авылына керә торган юлга кадәр уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап көньякка 1,6 км бара, аннары, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 950 м һәм көньяк чиге буйлап көнчыгышка 1,5 км дәвам итә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 2,1 км көньяк-көнбатышка һәм 1,4 км көньяк-көнчыгышка 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Спас муниципаль районы" муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы<br>турында" Татарстан Республикасы Законына<br>9 нчы кушымта

**Спас муниципаль районының "Иске Рәҗәп авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Иске Рәҗәп авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге Чәчәкле авыл җирлеге, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә Иске Рәҗәп, Чәчәкле авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Рәҗәп авылыннан 3,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Иске Рәҗәп авыл җирлеге, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Нәлет авылыннан 300 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 40 нчы (2 нче) тоташу ноктасына кадәруза.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 40 нчы (2 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Иске Рәҗәп, Чәчәкле авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Чәчәкле авылыннан 4,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге чиге Чәчәкле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 104, 103, 102, 101, 100, 99, 98 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап көнбатышка 6,9 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,1 км, көньяк-көнбатышка 50 м бара, аннары көньяк-көнбатышка 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, "КИМ" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м бара, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м һәм 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Спас муниципаль районы" муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"<br>Татарстан Республикасы Законына<br>10 нчы кушымта

## Спас муниципаль районының "КИМ" авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама "КИМ" авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

"КИМ" авыл җирлеге Аграмак, Антоновка, Куралово, Кызыл Бистә, Никольский, Ямбакты авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш.

"КИМ" авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә "КИМ", Кызыл Бистә авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куралово авылыннан 10,4 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 397798,59, Y = 1315465,17 координаталы 11 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буенча "КИМ", Куралово авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куралово авылыннан 10,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 403480,35, Y = 1320216,74 координаталы 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"КИМ" авыл җирлеге чиге Куралово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка Утюшка елгасы тамагына кадәр 15,3 км бара, аннары әлеге елга агымы буенча 6,1 км өскә таба бара, аннары көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 850 м, "Алексеевск – Югары Колок" – Базяково – Тукай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,4 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 1,9 км уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка "КИМ", Куралово һәм Ямбакты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ярдәм поселогыннан 3,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"КИМ" авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,5 км көньяк-көнчыгышка һәм, урман полосасын кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр уза, әлеге автомобиль юлы буйлап 800 м көньяк-көнбатышка "КИМ", Ямбакты һәм Аграмак авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 3,8 км көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

"КИМ" авыл җирлеге чиге Аграмак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка Болгар – Базарлы Матак автомобиль юлы буйлап 3,1 км уза, аннары көньякка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 450 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 700 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,3 км көньяк-көнбатышка "КИМ", Аграмак һәм Антоновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"КИМ" авыл җирлеге чиге Антоновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка 200 м, алга таба көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 800 м, сазлыкның көньяк чиге буйлап 50 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м бара, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 500 м "Алексеевск – Югары Колок" – Базяково – Тукай автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап төньякка 300 м бара, аннары көнбатышка авыл хуҗалыгы

җирләре буенча 850 м, сазлыкның төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, сазлыкның төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, урман полосасының төньяк чиге буйлап 150 м һәм, "КИМ" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кабат авыл хуҗалыгы җирләре буенча 2,4 км уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 300 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, урман полосасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 1,4 км, көньяк-көнчыгышка 150 м һәм кабат көньяк-көнбатышка 450 м "КИМ", Антоновка һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында "КИМ" совхозының икенче ферма поселогыннан 3,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"КИМ" авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м уза, аннары "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньякка 150 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 400 м бара, алга таба көньяк-көнбатышка, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м, әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, кабат әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, аннары 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка 700 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 600 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 50 м, төньяк-көнбатышка 200 м уза, аннары әлеге урман кварталының көньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 300 м уза, шуннан соң 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 550 м һәм, сазлыкны һәм Бездна елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 400 м уза, алга таба 33 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка 50 м һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча төньякка 1,1 км бара, аннары төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, 33 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 250 м инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,0 км аска таба бара, алга таба төньяк-көнбатышка күл буенча 200 м, инеш агымы буенча 150 м аска таба, күл буенча 50 м, кабат инеш агымы буенча 1,4 км аска таба аның Куйбышев сусаклагычына койган җиренә кадәр бара, әлеге сусаклагычның сулъяк яры буйлап 850 м төньяк-көнбатышка "КИМ", Никольский һәм Кызыл Бистә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ширбәт авылыннан 500 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"КИМ" авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка Куйбышев сусаклагычы буйлап утрауга кадәр 9,4 км уза, әлеге утрауның төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,6 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 2,6 км бара, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 1,4 км көньякка сулъяк ярга кадәр бара һәм Куйбышев сусаклагычының сулъяк яры буйлап 9,5 км

көньяк-көнбатышка 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында" Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Кызыл Бистә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Кызыл Бистә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кызыл Бистә авыл җирлеге "КИМ", Никольский, Полянка, Приволжский, Өчкүл авыл җирлекләре, Кама Тамагы муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кызыл Бистә, Приволжский авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ржавец авылыннан 9,3 км төньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 397116,91, Y = 1310102,39 координаталы 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Кызыл Бистә, "КИМ" авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куралово авылыннан 10,4 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 397798,59, Y = 1315465,17 координаталы 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге "КИМ" авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка Куйбышев сусаклагычы буйлап утрауга кадәр 9,4 км уза, әлеге утрауның төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,6 км һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 2,6 км бара, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 1,4 км көньякка сулъяк ярга кадәр бара һәм Куйбышев сусаклагычының сулъяк яры буйлап 9,5 км көньяк-көнбатышка Кызыл Бистә, "КИМ" һәм Никольский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ширбәт авылыннан 500 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып Ясачка елгасы агымы буенча 1,5 км өскә таба аңа инеш койган урынга кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча өскә таба 500 м бара, көньяк-көнчыгышка сазлык буенча 50 м уза, аннары көньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 650 м, "Болгар урманчылыгы"

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 25, 26, 27 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буенча, сынык сызык ясап, 5,3 км, сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча сазлыкка кадәр 450 м бара, алга таба әлеге сазлыкның көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка 200 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча уза, аннары көньяк-көнбатышка сазлык буйлап 950 м, берничә тапкыр сазлыкны һәм ике тапкыр урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км бара, сазлык буенча, сынык сызык ясап, көнбатышка 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка, 1,1 км көньяк-көнчыгышка, 400 м төньяк-көнчыгышка һәм 1,2 км көньяк-көнчыгышка Кызыл Бистә, Никольский авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Бугровка авылыннан 4,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр дәвам итә.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Кызыл Бистә, Полянка авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 4,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Полянка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кызыл Бистә, Полянка һәм Өчкүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 5,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км көньяк-көнбатышка 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кызыл Бистә, Өчкүл һәм Приволжский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Вал авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 650 м, көньяк-көнчыгышка 900 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 5,3 км 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кызыл Бистә авыл җирлеге чиге Приволжский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, сынык сызык ясап, көньякка 9,5 км сулъяк ярга кадәр уза, алга таба көньякка "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 49, 58, 65 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 3,4 км, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м бара, аннары 64 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 450 м уза, алга таба көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-

көнбатыш чиге буйлап 800 м уза, аннары урман полосасының көньяк чиге буйлап 950 м көнбатышка бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 900 м, көньяк-көнбатышка 350 м Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр уза, әлеге автомобиль юлы буенча төньяк-көнбатышка 3,0 км бара, аннары көньяк-көнбатышка, дамбаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Кузнечиха авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Кузнечиха авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кузнечиха авыл җирлеге Урта Йорткүл, Чәчәкле авыл җирлекләре, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Кузнечиха авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кузнечиха, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урманасты Йорткүл авылыннан 5,1 км көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Кузнечиха, Чәчәкле авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Йолдыз авылыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кузнечиха авыл җирлеге чиге Чәчәкле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 550 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,8 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 200 м, төньяк-көнбатышка 300 м бара, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, чокыр төбе буйлап 800 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 1,3 км чокырларны кисеп уза, канау буенча 300 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 300 м, көньяк-көнчыгышка 200 м бара, шуннан соң "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок

урманчылыгындагы 83 урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 50 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м, урман полосасы буйлап 650 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м Кузнечиха, Чәчәкле авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Покровка авылыннан 2,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кузнечиха авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Кузнечиха, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Покровка авылыннан 3,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кузнечиха авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 1,2 км, көнбатышка 250 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 350 м, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м уза, урман полосасының көньяк чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 450 м, сазлыкның көньяк чиге буйлап 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,1 км һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 100 м, ярның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, ике тапкыр чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 750 м, "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 79 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,8 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, көньякка 1,3 км, төньяк-көнбатышка 1,8 км, көньякка 750 м бара, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 1,0 км, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 100 м, урман массивы буенча 150 м бара, шуннан соң урман массивы буйлап төньяк-көнбатышка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
13 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Куралово авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Куралово авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Куралово авыл җирлеге Әҗмәр, "КИМ", Ямбакты авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш.

Куралово авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Куралово, "КИМ" авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куралово авылыннан 10,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=403480,35, Y=1320216,74 координаталы 14 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буенча Куралово, Әҗмәр авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Әҗмәр авылыннан 7,6 км төньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=405887,08, Y = 1324434,98 координаталы 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Куралово авыл җирлеге чиге Әҗмәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 12,2 км көньяк-көнчыгышка Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап сусаклагычка инеш койган җиргә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 1,7 км өскә таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка сазлык буенча 50 м, сазлыкның төньяк чиге буенча 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,7 км һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м Әҗмәр авылына керә торган юлга кадәр уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап көньякка 1,6 км бара, аннары, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 850 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 950 м һәм көньяк чиге буйлап көнчыгышка 1,5 км дәвам итә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 2,1 км көньяк-көнбатышка һәм 1,4 км көньяк-көнчыгышка Куралово, Әҗмәр һәм Ямбакты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Екатериновка авылыннан 4,4 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Куралово авыл җирлеге чиге Ямбакты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 200 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,8 км Куралово, Ямбакты һәм "КИМ" авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ярдәм поселогыннан 3,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Куралово авыл җирлеге чиге "КИМ" авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка Утюшка елгасы тамагына кадәр 15,3 км бара, аннары әлеге елга агымы буенча 6,1 км өскә таба бара, аннары көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 850 м,

"Алексеевск – Югары Колок" – Базяково – Тукай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,4 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 1,9 км уза, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"<br>Татарстан Республикасы Законына<br>14 нче кушымта

**Спас муниципаль районының<br>"Никольский авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге<br>территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Никольский авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Никольский авыл җирлеге Антоновка, "КИМ", Кызыл Бистә, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Никольский авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Никольский, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Отрада авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буенча Никольский, Кызыл Бистә авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Бугровка авылыннан 4,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Никольский авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Никольский, Кызыл Бистә һәм "КИМ" авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ширбәт авылыннан 500 м көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып Ясачка елгасы агымы буенча 1,5 км өскә таба аңа инеш койган урынга кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча өскә таба 500 м бара, көньяк-көнчыгышка сазлык буенча 50 м уза, аннары көньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, 650 м, "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 25, 26, 27 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буенча, сынык сызык ясап, 5,3 км, сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча сазлыкка кадәр 450 м бара, алга таба әлеге сазлыкның көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка 200 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән

полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча уза, аннары көньяк-көнбатышка сазлык буйлап 950 м, берничә тапкыр сазлыкны һәм ике тапкыр урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км бара, сазлык буенча, сынык сызык ясап, көнбатышка 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнчыгышка, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнбатышка, 1,1 км көньяк-көнчыгышка, 400 м төньяк-көнчыгышка һәм 1,2 км көньяк-көнчыгышка 13 нче тоташу ноктасына кадәр дәвам итә.

Никольский авыл җирлеге чиге "КИМ" авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Никольский, "КИМ" һәм Антоновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында "КИМ" совхозының икенче фермасы поселогыннан 3,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м уза, аннары "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньякка 150 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 400 м бара, алга таба көньяк-көнбатышка, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м, әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, кабат әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, аннары 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка 700 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка 600 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 50 м, төньяк-көнбатышка 200 м уза, аннары әлеге урман кварталының көньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 300 м уза, шуннан соң 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 550 м һәм, сазлыкны һәм Бездна елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 400 м уза, алга таба 33 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка 50 м һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча төньякка 1,1 км бара, аннары төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, 33 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 250 м инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,0 км аска таба бара, алга таба төньяк-көнбатышка күл буенча 200 м, инеш агымы буенча 150 м аска таба, күл буенча 50 м, кабат инеш агымы буенча 1,4 км аска таба аның Куйбышев сусаклагычына койган җиренә кадәр бара, әлеге сусаклагычның сулъяк яры буйлап 850 м төньяк-көнбатышка 12 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Никольский авыл җирлеге чиге Антоновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Йорткүл, Никольский һәм Антоновка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кырый Йорткүл авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,2 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 750 м, сазлык буйлап 200 м, күл буйлап 100 м уза, алга таба төньяк-көнчыгышка сазлык буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасы буенча 2,5 км, сазлык буйлап 100 м Лахтур инешенә кадәр бара, аннары әлеге инеш агымы буенча 450 м аска таба буага

кадәр уза, әлеге буаның уңъяк яры буйлап төньяк-көнбатышка 2,8 км бара, алга таба "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка 300 м уза, аннары төньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кабат 42 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 700 м бара, алга таба 40 нчы, 41 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 2,2 км уза, аннары 41, 39, 37 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,4 км төньяк-көнбатышка 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Никольский авыл җирлеге чиге Урта Йорткүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 600 м, чокырны, "Ким" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка" – Кырый Йорткүл – "Никольский – Отрада" автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, сазлыкны кисеп үтеп, көнбатышка 3,1 км һәм төньякка 200 м 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
15 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Полянка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Полянка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Полянка авыл җирлеге Кызыл Бистә, Өчкүл авыл җирлекләре, Тәтеш муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Полянка авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Полянка, Кызыл Бистә авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 4,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Полянка авыл җирлеге, Тәтеш муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 9 нчы (3 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Полянка авыл җирлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә

9 нчы (3 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буенча Полянка, Өчкүл авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Үрнәк авылыннан 5,6 км көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Полянка авыл җирлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Полянка, Өчкүл һәм Кызыл Бистә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 5,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 3,4 км төньяк-көнбатышка кибеп баручы инешкә кадәр үтә, шуннан соң әлеге инеш агымы буенча өскә таба 150 м уза, аннары күл буйлап төньяк-көнбатышка 100 м, кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 1,0 км плотинага кадәр дәвам итә, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка, плотинаны төньяк-көнчыгыш ягыннан әйләнеп узып, 50 м бара, буаның сулъяк яры буйлап көнбатышка 50 м уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба күлгә кадәр 400 м, күл буйлап төньяк-көнбатышка 100 м бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча кабат өскә таба күлгә кадәр 250 м уза, күл буйлап төньяк-көнбатышка 50 м бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 3,6 км дәвам итә, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,1 км уза, сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,3 км, сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,2 км, төньяк-көнчыгышка 800 м Өчкүл – Балымер автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, төньяк-көнбатышка 1,6 км һәм көнбатышка 1,1 км бара, аннары "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап көнбатышка 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м, 39 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м бара, шуннан соң 38 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 500 м уза, алга таба 37 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,2 км һәм төньяк чиге буйлап көнбатышка 1,1 км Куйбышев сусаклагычының сулъяк ярына кадәр дәвам итә, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 3,7 км көнбатышка 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Полянка авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 400 м бара, алга таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 1,1 км 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"<br>Татарстан Республикасы Законына<br>16 нчы кушымта

**Спас муниципаль районының "Приволжский авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Приволжский авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Приволжский авыл җирлеге "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге, Кызыл Бистә, Өчкүл авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш.

Приволжский авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Приволжский авыл җирлеге, "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 7,3 км төньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Приволжский, Кызыл Бистә авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ржавец авылыннан 9,3 км төньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=397116,91, Y=1310102,39 координаталы 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Приволжский авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, сынык сызык ясап, көньякка 9,5 км сулъяк ярга кадәр уза, алга таба көньякка "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 49, 58, 65 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 3,4 км, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м бара, аннары 64 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 450 м уза, алга таба көньяк-көнчыгышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 800 м уза, аннары урман полосасының көньяк чиге буйлап 950 м көнбатышка бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 900 м, көньяк-көнбатышка 350 м Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр уза, әлеге автомобиль юлы буенча төньяк-көнбатышка 3,0 км бара, аннары көньяк-көнбатышка, дамбаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча, 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Приволжский, Кызыл Бистә һәм Өчкүл авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Вал авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Приволжский авыл җирлеге чиге Өчкүл авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 2,0 км, төньяк-көнбатышка 250 м урман полосасына кадәр бара, әлеге урман полосасының көнбатыш чиге буйлап төньякка 1,5 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 950 м

Приволжский, Өчкүл авыл җирлекләре һәм "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 3,1 км көньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Приволжский авыл җирлеге чиге "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, көньякка 8,4 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча сулъяк ярга кадәр уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 200 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм чокырларны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 650 м, көнбатышка 350 м, көньяк-көнчыгышка 100 м аэродромга кадәр бара, аэродром буенча көньяк-көнчыгышка 650 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 650 м, төньяк-көнчыгышка 700 м, саклау валын һәм "Базарлы Матак – Болгар" – Ржавец автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка 1,0 км, көньяк-көнбатышка 150 м уза, аннары урман массивының көнбатыш чиге буенча көньякка 150 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка, урман массивын һәм сакланулы урман полосасын кисеп үтеп, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр 750 м бара, аннары әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буенча көнчыгышка 600 м уза, алга таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 300 м 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
17 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Урта Йорткүл авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Урта Йорткүл авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Урта Йорткүл авыл җирлеге Аграмак, Антоновка, Кузнечиха, Никольский авыл җирлекләре, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Кузнечиха, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Кузнечиха авылыннан 4,9 км көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Никольский, Урта Йорткүл авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Кырый

Йорткүл авылыннан 4,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Никольский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Йорткүл, Антоновка һәм Никольский авыл җирлекләре тоташкан урында Кырый Йорткүл авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 600 м, чокырны, "Ким" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка" – Кырый Йорткүл – "Никольский – Отрада" автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, сазлыкны кисеп үтеп, көнбатышка 3,1 км һәм төньякка 200 м 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Антоновка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Йорткүл, Антоновка һәм Аграмак авыл җирлекләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км, "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 550 м бара, Бездна елгасын, яр буе агач-куак массивын, сазлыкны һәм "КИМ" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 4,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буенча 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Аграмак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Йорткүл, Аграмак авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Фадеевка авылыннан 2,2 км төньякта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буенча 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Урта Йорткүл, Кузнечиха авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урманасты Йорткүле авылыннан 5,1 км көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Урта Йорткүл авыл җирлеге чиге Кузнечиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 1,2 км, көнбатышка 250 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 350 м, «КИМ» – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м уза, урман полосасының көньяк чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 450 м, сазлыкның көньяк чиге буйлап 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,1 км һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка 100 м, ярның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, ике тапкыр чокырны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 750 м, "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 79 нчы урман

кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,8 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, көньякка 1,3 км, төньяк-көнбатышка 1,8 км, көньякка 750 м бара, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 1,0 км, урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 100 м, урман массивы буенча 150 м бара, шуннан соң урман массивы буйлап төньяк-көнбатышка 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
18 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Өчкүл авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Өчкүл авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Өчкүл авыл җирлеге "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге, Кызыл Бистә, Полянка, Приволжский авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш.

Өчкүл авыл җирлеге чиге Тәтеш муниципаль районы белән чиктәш җирдә Өчкүл, Полянка авыл җирлекләре һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Үрнәк авылыннан 5,6 км көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 5 нче тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Өчкүл авыл җирлеге, "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге һәм Тәтеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Үрнәк авылыннан 5,3 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Өчкүл авыл җирлеге чиге "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Өчкүл авыл җирлеге, "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге һәм Приволжский авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Приволжский поселогыннан 3,1 км көньякта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 50 м, урман массивының төньяк чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча Болгар – Танкеевка автомобиль юлына кадәр 1,2 км бара, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буенча көньякка 750 м уза, аннары, әлеге автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл

хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 350 м бара, аннары, сынык сызык ясап, "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 29 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап көньяк-көнбатышка 1,3 км, 28 нче урман кварталы буйлап 1,7 км бара, аннары 28 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буенча 2,5 км төньяк-көнбатышка уза, алга таба 14, 13, 12 нче урман кварталларының көньяк чиге буенча көнбатышка 3,1 км Куйбышев сусаклагычының сулъяк ярына кадәр уза, сусаклагыч акваториясе буйлап 2,0 км 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Өчкүл авыл җирлеге чиге Приволжский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Өчкүл, Приволжский, Кызыл Бистә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красный Вал авылыннан 2,3 км көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,4 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 2,0 км, төньяк-көнбатышка 250 м урман полосасына кадәр бара, шуннан соң әлеге урман полосасының көнбатыш чиге буйлап төньякка 1,5 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 950 м 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Өчкүл авыл җирлеге чиге Кызыл Бистә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 650 м, көньяк-көнчыгышка 900 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 5,3 км Өчкүл, Кызыл Бистә һәм Полянка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Танкеевка авылыннан 5,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Өчкүл авыл җирлеге чиге Полянка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 3,4 км төньяк-көнбатышка кибеп баручы инешкә кадәр үтә, шуннан соң әлеге инеш агымы буенча өскә таба 150 м уза, аннары күл буйлап төньяк-көнбатышка 100 м, кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 1,0 км плотинага кадәр дәвам итә, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка, плотинаны төньяк-көнчыгыш ягыннан әйләнеп узып, 50 м бара, буаның сулъяк яры буйлап көнбатышка 50 м уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба күлгә кадәр 400 м, күл буйлап төньяк-көнбатышка 100 м бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча кабат өскә таба күлгә кадәр 250 м уза, күл буйлап төньяк-көнбатышка 50 м бара, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 3,6 км дәвам итә, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,1 км уза, сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,3 км, сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,2 км, төньяк-көнчыгышка 800 м Өчкүл – Балымер автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 850 м, төньяк-көнбатышка 1,6 км һәм көнбатышка 1,1 км бара, аннары "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет

учреждениесенең Спас участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап көнбатышка 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м, 39 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м бара, шуннан соң 38 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 500 м уза, алга таба 37 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка 1,2 км һәм төньяк чиге буйлап көнбатышка 1,1 км Куйбышев сусаклагычының сулъяк ярына кадәр дәвам итә, аннары Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 3,7 км көнбатышка 5 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
19 нчы кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Чәчәкле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Чәчәкле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Чәчәкле авыл җирлеге Иске Рәҗәп, Кузнечиха авыл җирлекләре, Әлки муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

Чәчәкле авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә Чәчәкле, Кузнечиха авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Йолдыз авылыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Чәчәкле, Иске Рәҗәп авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Иске Рәҗәп авылыннан 3,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Чәчәкле авыл җирлеге чиге Иске Рәҗәп авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юхмачы участок урманчылыгындагы 104, 103, 102, 101, 100, 99, 98 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап көнбатышка 6,9 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 1,1 км, көньяк-көнбатышка 50 м бара, аннары көньяк-көнбатышка 200 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, "КИМ" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м бара, аннары урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге

буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км Чәчәкле, Иске Рәҗәп авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Чәчәкле авылыннан 4,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Чәчәкле авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Чәчәкле, Кузнечиха авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Покровка авылыннан 2,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Чәчәкле авыл җирлеге чиге Кузнечиха авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 550 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 1,8 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча, "КИМ" – Кузнечиха – Лесная Хмелевка автомобиль юлын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка 200 м, төньяк-көнбатышка 300 м бара, аннары урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, чокыр төбе буйлап 800 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 1,3 км чокырларны кисеп уза, канау буенча 300 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 300 м, көньяк-көнчыгышка 200 м бара, шуннан соң "Әлки урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Черная Речка участок урманчылыгындагы 83 урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 50 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м, урман полосасы буйлап 650 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

"Спас муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында" Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

**Спас муниципаль районының**
**"Ямбакты авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Ямбакты авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы

Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ямбакты авыл җирлеге Аграмак, Бураково, Әҗмәр, "КИМ", Куралово авыл җирлекләре, Алексеевск һәм Әлки муниципаль районнары белән чиктәш.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә Ямбакты, Бураково авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Танино авылыннан 3,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Ямбакты авыл җирлеге, Алексеевск һәм Әлки муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Танино авылыннан 5,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче (31 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Әлки муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче (31 нче) тоташу ноктасыннан алып Спас муниципаль районы чиге буйлап Ямбакты, Аграмак авыл җирлекләре һәм Әлки муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ямбакты авылыннан 4,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Аграмак авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып 3,5 км төньяк-көнбатышка Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 3,5 км бара, аннары, әлеге автомобиль юлын һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 100 м бара, алга таба "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 63 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча көньякка 650 м һәм көньяк чиге буенча көнбатышка 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка 550 м, төньяк-көнбатышка 100 м бара, аннары 65 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка 950 м, төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 250 м, көнбатыш чиге буйлап көньякка 200 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка 350 м уза, алга таба, урман массивын, урман полосасын һәм Аграмак – Ямбакты автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 2,1 км бара, шуннан соң 64 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап көньякка 400 м, урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м уза, аннары әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча көньякка 350 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка 450 м дәвам итә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка 100 м, әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м бара, аннары 61 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,2 км һәм, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 400 м Ямбакты, Аграмак һәм "КИМ" авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тукай авылыннан 3,8 км көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге "КИМ" авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямбакты, "КИМ" һәм Куралово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ярдәм

поселогыннан 3,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,5 км көньяк-көнчыгышка һәм 1,2 км көньяк-көнбатышка, урман полосасын кисеп үтеп, Базарлы Матак – Болгар автомобиль юлына кадәр бара, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап көньяк-көнбатышка 800 м 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Куралово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямбакты, Куралово һәм Әҗмәр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Екатериновка авылыннан 4,4 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка 200 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,8 км 15 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Әҗмәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ямбакты, Әҗмәр һәм Бураково авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ямбакты авылыннан 5,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка 650 м бара, чокырны кисеп чыгып, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, урман полосасы буенча 450 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ямбакты авыл җирлеге чиге Бураково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка 2,2 км, көньякка 650 м, төньяк-көнбатышка 250 м уза, аннары "Болгар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Никольский участок урманчылыгындагы 53 нче урман кварталының төньяк чиге буенча, сынык сызык ясап, көнбатышка 850 м һәм көнбатыш чиге буенча көньякка 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 200 м, көньяк-көнбатышка 400 м, төньякка 2,0 км, көнбатышка 1,4 км урман полосасына кадәр уза, әлеге урман полосасының көньяк чиге буенча көнбатышка 450 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка 700 м, урман массивын кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнбатышка 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — Татарстан Республикасы Президенты Аппараты / Аппарат Президента Республики Татарстан

Казан,Кремль
2014 елның 22 ноябре
№ 100-ТРЗ